**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ЛАИШЕВСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**СОВЕТ МАЛОЕЛГИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

422619 с. Малая Елга
тел: 8-(278) -3-25-16
факс: 8-(278) -3-25-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КЕЧЕ ЕЛГА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

422619 а. Рече.Елга
тел: 8-(278) -3-25-16
факс: 8-(278) -3-25-16

---

2020елның 22 декабрендәге 19 номер

**КАРАР**

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 ноябрендәге 21 номерлы "Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә" карарына үзгәрешләр кертү хакында**

**»**

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, "Коррупциягә каршы көрәш турында" 2008елның 25 декабрендәге 273-ФЗ Федераль закон, 2013елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы белән, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлеге Уставы нигезендә Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Кече Елга авыл җирлеге советының 2018елның 27 ноябрендәге 21 номерлы «Лаеш муниципаль районының Кече Елга авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә» карарына, кушымта нигезендә. үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча рәсми порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм җирлек территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикас**
**Лаеш муниципаль районы**
**Кече Елга авыл җирлеге Советы рәисе** **Л.А.Кыямова**

2020 елның 22 декабрендәге 19 номерлы
Лаеш муниципаль районының
Кече Елга авыл җирлеге
Советы Карарына

кушымта

**Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 ноябрендәге 21 номерлы "Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Кече Елга авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә" карарына үзгәрешләр кертү**

1) 28 статьяның 10 пунктындагы 2 пунктчасында түбәндәге:

«хезмәт эшчәнлеге, хезмәт стажы турында документлар» сүзләреннән соң "(2020 елның 1 гыйнварына кадәр чорлар өчен)" сүзләрен өстәргә;

2) 34 бүлекнең 4 пунктын түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга:

"(булган очракта), муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәтне узу чорында хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр формалаштыру һәм күрсәтелгән белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру";

1) 19 бүлекнең 3 пунктындагы 4 пунктчасына түбәндәге сүзләр өстәргә:
«хезмәт кенәгәсен» сүзләреннән соң «хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр» сүзләрен өстәргә;

2) 19 бүлекнең 3 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«мәҗбүри пенсия иминләштерүенең иминият таныклыгы» сүзләрен «индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ» сүзләренә алмаштырырга;

3) 32 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
дисциплинар түләтүләрне куллану һәм бетерү тәртибе, әлеге Федераль законда каралган очраклардан тыш, хезмәт законнары белән билгеләнә.;

1) 6 нчы пункт 28 бүлектә түбәндәге сүзләрне үзгәртү:
«ә стаж дәвамлылыгы һәм айлык түләүләр әлеге Кодекс нигезендә тиешле еллар эшләгән өчен пенсия күләмен билгеләгәндә муниципаль хезмәткәргә билгеләнгән шундый ук күрсәткечләрдә исәпкә алына» сүзләрен «, ә класслы чин өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативларын билгели торган билгеләмәсендә исәпкә алына» сүзләренә алмаштырырга;;

1) Подпункт 2 пункта 1 раздела 16 исключить слова «садоводческого, огороднического, дачного потребительских кооперативов»;

3) 18 статьяның 13 пунктын түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга:
җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затын» сүзләрен «яисә күрсәтелгән затларга карата җаваплылыкның башка чараларын куллану» сүзләренә алмаштырырга;

4) 16 бүлекнең 1 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында түләүсез нигездә катнашу,съездда (конференциядә) яисә башка иҗтимагый оешманың, торак, торак төзелеше, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтенең гомуми җыелышында катнашу;

б) коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел һөнәр берлеге оешмасының сайланулы органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында катнашу, яллаучының Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән тәртиптә алынган вәкиле рөхсәте белән съездда (конференциядә) яисә башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашу (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү;

г) муниципаль берәмлек гамәлгә куючы (катнашучы) булып торган муниципаль хокукый актлар нигезендә, муниципаль берәмлек исеменнән оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен яисә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә, идарә органнарында һәм оешманың ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар.